**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында**

2022 елда «Сабан туе» татар халык бәйрәмен үткәрү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге срокларда уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә дә) – 2022 елның 11-13 июнендә;

Чаллы шәһәрендә – 2022 елның 18 июнендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2022 елның 19 июнендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән срокларда уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән вакытларда оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 16 май
№ ПУ-334